УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О Республиканской межведомственной комиссии по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и использования иностранных работников в Республике Татарстан»**

В целях реализации статей 6 и $6^1$ Федерального закона от 25 июля 2002 года № 115-ФЗ «О правовом положении иностранных граждан в Российской Федерации» **постановляю:**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 25 февраля 2014 года № УП-217 «О Республиканской межведомственной комиссии по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и использования иностранных работников в Республике Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 22 ноября 2014 года № УП-1065, от 30 июля 2015 года № УП-688, от 20 марта 2017 года № УП-231, от 3 июня 2017 года № УП-459, от 14 октября 2017 года № УП-911, от 2 февраля 2019 года № УП-58, от 5 июня 2020 года № УП-339 и от 18 февраля 2021 года № УП-154) следующие изменения:

а) в Указе:

в преамбуле слова «в соответствии со статьями $13^3$ и $18^1$» заменить словами «в соответствии со статьями 6, $6^1$, $13^3$ и $18^1$»;

пункт 4 дополнить абзацем следующего содержания:

«по ежегодной подготовке мотивированных предложений по определению для Республики Татарстан квоты на выдачу иностранным гражданам и лицам без гражданства разрешений на временное проживание в Российской Федерации на следующий календарный год в установленном законодательством порядке.»;

б) в пункте 3 Положения о Республиканской межведомственной комиссии по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и использования иностранных работников в Республике Татарстан:

дополнить новыми абзацами шестнадцатым и семнадцатым следующего содержания:

«рассмотрение заявок-анкет о выделении квоты на выдачу иностранному гражданину и лицу без гражданства разрешения на временное проживание в Российской Федерации (далее – заявка-анкета);

принятие решения о выделении квоты на выдачу иностранным гражданам и лицам без гражданства разрешений на временное проживание в Российской Федерации либо об отказе в ее выделении по заявкам-анкетам;»;

абзац шестнадцатый считать абзацем восемнадцатым;

в) в составе Республиканской межведомственной комиссии по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и использования иностранных работников в Республике Татарстан (далее – Комиссия):

вывести из состава Комиссии М.С. Дулкарнаева;

ввести в состав Комиссии Олейника Павла Михайловича – первого заместителя руководителя следственного управления Следственного комитета Российской Федерации по Республике Татарстан (по согласованию).

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
02 марта 2021 года
№ УП-194

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 6 һәм $6^1$ статьяларын гамәлгә ашыру максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» 2014 елның 25 февралендәге ПУ-217 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 ноябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2015 елның 30 июлендәге ПУ-688 номерлы, 2017 елның 20 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-459 номерлы, 2017 елның 14 октябрендәге ПУ-911 номерлы, 2019 елның 2 февралендәге ПУ-58 номерлы, 2020 елның 5 июнендәге ПУ-339 номерлы һәм 2021 елның 18 февралендәге ПУ-154 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Указда:

преамбулада «$13^3$ һәм $18^1$ статьялары нигезендә» сүзләрен «6, $6^1$, $13^3$ һәм $18^1$ статьялары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«законнарда билгеләнгән тәртиптә киләсе календарь елына чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Россия Федерациясендә вакытлыча яшәргә рөхсәт бирү өчен Татарстан Республикасында квоталар билгеләүгә кагылышлы дәлилле тәкъдимнәрне ел саен әзерләү буенча.»;

б) Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәнең 3 пунктында:

түбәндәге эчтәлекле яңа уналтынчы һәм унҗиденче абзацлар өстәргә:

«чит ил гражданына һәм гражданлыгы булмаган затка Россия Федерациясендә вакытлыча яшәргә рөхсәт бирү өчен квота бүлеп бирү турында гариза-анкеталарны (алга таба – гариза-анкета) карау;

гариза-анкеталар буенча чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Россия Федерациясендә вакытлыча яшәргә рөхсәт бирү

өчен квота бүлеп бирү яисә аны бүлеп бирүдән баш тарту турында карар кабул итү;»;

уналтынчы абзацны унсигезенче абзац дип санарга;

в) Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан М.С. Дөлкәрнәевны чыгарырга;

Комиссия составына Олейник Павел Михайловичны – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесенең беренче урынбасарын (килешү буенча) кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миннеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 02 март
№ ПУ-194